Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел №91

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 79 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 79 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 110 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 132 номерлы, 2020 елның 18 маендагы 89 номерлы, 2020 елның 19 ноябрендәге 6 номерлы, 2023 елның 26 сентябрендәге 73 номерлы, 2023 елның 18 декабрендәге 80 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (территорияләргә) карата казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр («урам-юл челтәре», «территорияне төзекләндерү» куллану төрләрен кертеп»).»;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы, Колшәрип авылы, Тукай урамы 50 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Колшәрип авыл
җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов